**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2019 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Руденко Гөлзадә Рәкыйп кызына – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директорына;

2) Фомин Анатолий Алексеевичка – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисенә;

3) Хухунашвили Маринэ Мануиловнага – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары, Казан шәһәренең «Сиони» грузин милли-мәдәни мохтарияте» җирле иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисенә;

4) «Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасына;

5) «ДЦП авырулы балалар» хәйриячелек фондына;

6) «Татарстан Республикасы удмурт милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасына;

7) Татарстан Республикасының «Гаилә канаты астында» төбәк иҗтимагый оешмасына;

8) Татарстан Республикасының «Без бергә!» тәрбиягә бала алган гаиләләрнең төбәк иҗтимагый оешмасына.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 11 октябрь
№ ПУ-615